# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы «Девәтернә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Нарат торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**21.11.2023.** **№ 1**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2023 елның 21 ноябрендә 08:00 сәг.тә уздырылган гражданнар җыены нәтиҗәләре турында түбәндәге сорау буенча гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

«2024 елда Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Девәтернә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Нарат торак пункты территориясендә, I төркем инвалидлардан, көндезге формада белем алучы студентлардан, 80 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан тыш, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны (контракт буенча хәрби хезмәттәгеләр, мобилизацияләнеп, үз теләкләре буенча китүчеләр) һәм аларның гаилә члennарын (бергә яшәүче әти-әниләре, тормыш иптәшләре, балигъ булган балалары) түләүдән азат итеп, яшәү урыны буенча теркәлгән һәм балигъ булган һәр кешедән 700 сум күләмендә үзара салым чаралары җыюны кертүгә һәм алардан җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен файдалануга ризамы:

- тракторны карап тоту һәм аңа хезмәт күрсәтү (МТЗ-82 тракторы өчен запас частьләр сатып алу; дизель ягулыгы һәм май сатып алу; шартнамә буенча тракторист хезмәте өчен түләү).
- Нарат авылында урамнарны яктырту өчен лампалар, дроссельләр, фонарьлар сатып алу, урнаштыру; шартнамә буенча электрик хезмәте өчен түләү.
- халыкны су белән тәэмин итү өчен тирәнлек насосларын һәм материалларны ремонтлау, аларга хезмәт күрсәтү, сатып алу, башка хезмәтләр.
- янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (запас частьлар, ягулык-майлау материаллары сатып алу һәм янгын сүндерү машинасы йөртүчесенең хезмәте өчен түләү).
- Нарат торак пунктында уңайлыклар булдыру (урамнарда чүп чабу).
- торак пункт чикләрендәге җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы юлларны карап тоту, ремонтлау (Нарат авылы урамнарын кардан чистарту).
- Бөек Ватан сугышында катнашучылар хөрмәтенә салынган һәйкәлне ремонтлау.
- Нарат торак пунктында хуҗалыклар, электр линияләре өчен куркыныч тудыручы һәм корыган агачларны кисү һәм чыгару

«РИЗА» «КАРШЫ».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 117 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны - 61 кеше, бу 52,1 % тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

"РИЗА" позициясе өчен гражданнар җыенында 61 катнашучы тавыш бирде; "КАРШЫ" позициясе өчен җыенда 0 катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы «Девәтернә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Нарат торак пунктында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләре - дөрес дип танырга.

2. 2024 елда Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы «Девәтернә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Нарат торак пункты территориясендә, I төркем инвалидлардан, көндезге формада белем алучы студентлардан, 80 яшькә җиткән ялгыз өлкән гражданнардан тыш, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны (контракт буенча хәрби хезмәттәгеләр, мобилизацияләнеп, үз теләкләре буенча китүчеләр) һәм аларның гаилә члennарын (бергә яшәүче әти-әниләре, тормыш иптәшләре, балигъ булган балалары), Россия Армиясендә хезмәт итүче һәм иректән мәхрүм итү урыннарындагы затларны түләүдән азат итеп, яшәү урыны буенча теркәлгән һәм балигъ булган һәр кешедән 700 сум күләмендә үзара салым чаралары җыюны кертергә.

3. Җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә:

**Нарат торак пункты территориясендә уңайлыклар булдыру кагыйдәләрен раслау, аларның үтәлешен контрольдә тоту, күрсәтелгән кагыйдәләр нигезендә торак пункт территориясендә уңайлыклар булдыруны оештыру:**

- МТЗ-82 тракторын карап тоту һәм аңа хезмәт күрсәтү (запас частьләр сатып алу; шартнамә буенча тракторист хезмәте өчен түләү);
- Нарат торак пунктында урамнарны яктырту өчен лампалар, фонарьлар сатып алу, урнаштыру, шартнамә буенча электрик хезмәте өчен түләү;
- Нарат торак пункты территориясендә уңайлыклау булдыру (урамнарда чүп чабу);
- Нарат авылында Бөек Ватан сугышында катнашучылар хөрмәтенә һәйкәл ясату һәм урнаштыру;
- Нарат торак пунктында хуҗалыклар, электр линияләре өчен куркыныч тудыручы һәм корыган агачларны кисү һәм чыгару.

**Нарат торак пунктында РФ законнарында каралган вәкаләтләр чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне оештыру:**

- халыкны су белән тәэмин итү (Нарат торак пунктында су белән тәэмин итү өчен тирәнлек насослары һәм материаллар сатып алу, ремонтлау, хезмәт күрсәтү, башка хезмәтләр күрсәтү).

**Нарат торак пункты чикләрендәге җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:**

- Нарат авылы урамнарын кардан чистарту;
- МТЗ-82 тракторы өчен дизель ягулыгы, май сатып алу;
- җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын ремонтлау һәм карап тоту буенча башка хезмәтләр.

**Нарат торак пункты чикләрендә янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү:**

- янгын сүндерү машинасын карап тоту, запас частьлар, ягулык-майлау материаллары сатып алу һәм янгын сүндерү машинасы йөртүчесенең хезмәте өчен түләү.

4. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендында элеп халыкка җиткерергә, “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (https://www.agryz.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Авыл җирлеге башлыгы Э.Э. ГАНИЕВ